СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
**КАРАРЫ**

**22 май 2023 ел** **№ 76**

**«Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» Яңа Кырлай авыл җирлегенең 20.02.2023 № 68 карарына үзгәрешләр кертү турында**

"Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясына ярашлы рәвештә, Яңа Кырлай авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. «Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмәне раслау турында» Яңа Кырлай авыл җирлегенең 20.02.2023 № 68 карары белән расланган Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16. "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясындагы 1 өлешендә каралган бурычны әлеге нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән гражданның яки затның үтәмәве аны биләгән вазыйфасыннан азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan.ru/) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге
башлыгы урынбасары

Д.З.Абдуллин